| | |
|---|---|
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**<br>**КҮЛЛЕ—КИМЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**<br>**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** | **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**<br>**КУЛЛЕ-КИМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО**<br>**ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО**<br>**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** |

422742, Атнинский район с. Кулле-Кими, ул. Кирова, 1А тел: 8(843-69) 3 - 53 - 40

«12» май 2020 ел №12

**Карар**

**2017 елның 28 февраль «Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең муниципаль мәгълүмат системаларының эшләве һәм алардан файдалану тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 4 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2019 елның 1 маендагы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»гы 71-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Әтнә районы прокуратурасының 2020 елның 29 апрелендагы протесты нигезендә Карар бирәм:

1. «Күлле-Киме авыл җирлегенең муниципаль мәгълүмат системаларының эшләве һәм алардан файдалану тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 28 февралендәге 4 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1. III бүлегендәге 3.7 пунктының 2 пунктчасында яңа редакциядә бәян итәргә:**

«2) сатып алуларның идентификацион кодлары һәм әлеге сатып алуларның план-графикларында булган (алга таба - план-графиклар), сатып алуларны тормышка ашыру турында хәбәрнамәләр, Тәэминатчыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү беркетмәләре, әлеге Федераль закон нигезендә сатып алуларда катнашучыларга бердәм мәгълүмат системасын кулланып җибәрелә торган контрактлар проектлары шартлары турында белешмәләр (алга таба-план-графиклар), контрактларны гамәлгә ашыру турында белешмәләр (алга таба-план-графиклар);»

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб – адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: (pravo.tatarstan.ru) веб –адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Күлле-Киме авыл җирлеге башкарма
җитәкчесе: Х.Х.Гәрәев